| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 27 май г.Казань № 646

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2020 ел, 25 август, 730 нчы карары белән расланган «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау» Татарстан Республикасы дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2020 ел, 25 август, 730 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 20 апрель, 263 нче, 2021 ел, 13 сентябрь, 870 нче, 2022 ел, 31 август, 927 нче, 2022 ел, 29 декабрь, 1455 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау» Татарстан Республикасы дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре | Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 552 140,07 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>2020 елда – 70 498,7 мең сум;<br>2021 елда - 107 435,7 мең сум;<br>2022 елда - 108 735,6 мең сум;<br>2023 елда - 88 490,0 мең сум;<br>2024 елда - 88 490,0 мең сум;<br>2025 елда - 88 490,0 мең сум.<br>Искәрмә. *Программаны финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, Татарстан Республикасы |

| | |
|---|---|
| | бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш». Программа чараларын тормышка ашыру өчен чараларны башкаручыларның төп эшчәнлеген финанслауга бүлеп бирелә торган акчаны, бюджеттан тыш акчаны (эшмәкәрләр, иганәчеләр акчасы) һәм муниципаль берәмлекләр бюджетлары акчасын җәлеп итү мөмкинлеге күздә тотыла»; |

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителеше

Программаны гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итү дәүләт финанславы нигезендә, шулай ук субсидияләр, грантлар рәвешендә ярдәм механизмнарын, инвестицияләр җәлеп итү, Татарстан Республикасы вәкиллекләренең матди-техник базасын, шулай ук Бөтендөнья татар конгрессы һәм Федераль татар милли-мәдәни автономиясе составына керүче иҗтимагый оешмаларны һәм законнарда тыелмаган башка чараларны кулланып гамәлгә ашырыла.

Ярдәмче программаны финанслауның гомуми күләме Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән 552 140,07 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:

2020 елда – 70 498,7 мең сум;
2021 елда - 107 435,7 мең сум;
2022 елда - 108 735,6 мең сум;
2023 елда - 88 490,0 мең сум;
2024 елда - 88 490,0 мең сум;
2025 елда - 88 490,0 мең сум.

Бюджеттан финанслау күләмнәре фараз характерында була һәм аларга, Татарстан Республикасы бюджеты мөмкинлекләрен исәпкә алып, ел саен төзәтмәләр кертелергә тиеш. Чаралар кысаларында финанслау күләмнәре Программага 1 нче кушымтада китерелгән.»;

Программаның IV бүлегендәге алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ел саен, хисап чорыннан (елыннан) соң килә торган елның 1 мартына кадәр Татарстан Республикасы Рәисенә, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Программаны гамәлгә ашыру эшләре барышы һәм финанс чараларыннан файдалануның нәтиҗәлелеге турында мәгълүмат.»;

Программага 1 нче, 2 нче кушымталарны яңа редакциядә (карарга теркәләләр) бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин